**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «22» ноябреннән № 292

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафларны түләү бурычларын түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2024 елның 10 гыйнварындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафларны түләү бурычларын түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2024 елның 10 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган (2024 елның 15 маендагы 140 номерлы, 2024 елның 26 сентябрендәге 241 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафларны түләү бурычларын түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча җирле бюджетка түләүләр түләү буенча бурычларның исәпкә алына торган суммалары турында бюджет керемнәре администраторы белешмәсе;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru/, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов